# ЧИШМӘ БАШЫ



Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча 8нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

№4 2025ел
февраль

***Ата –аналар һәм балалар өчен мәгълүмати-танып белү газетасы***

## Бу санда:

- Тел турында шигырьләр, мәкальләр
- Муса Җәлил - патриот шагыйрь
- 21 нче февраль - Халыкара туган тел көне
- Ватанны саклаучылар көне

**Туган телем**

"Әннә" диеп, "Әттә" диеп
Ачылган безнең телләр.
Туган телдә бишек җырын
Тыңлап үзгәндир төннәр.

Әлифбадан хәреф танып
Укый-яза башладык.
Туган телдә белем алып,
Күп ачышлар ясадык.

Без дә үстек, дөньялар да
Киңәйде инде хәзер.
Туган телне галәмгә дә
Илтергә бүген әзер.

Туган телем, газиз телем,
Син – галәмнең ачкычы.
Туган телең юкка чыгу –
Кайгының иң ачысы.

Туган телем — татар теле,
Син — гомерлек юлдашым.
"Туган тел мәңге яшәсен!" -
Ул бит гомерем юл башы.

*Раил Гатауллин. 20.02.2015*

Ана теле бер булыр.

Туган тел үзе өчен, башка тел көнем өчен.

Туган телне кадерләгән халык кадерле булыр.

Татлы тел тимер капканы ачар.

Иле барның теле бар.





# *Муса Җәлил – патриот шагыйрь*



15 нче февраль - Татар халкының бөек улы, герой шагыйрь Муса Җәлилнең туган көне. Татар халкының каһарман улы, герой-шагыйрь Муса Җәлил (Муса Мостафа улы Җәлилов) 1906 елның 15 февралендә элекке Оренбург губернасы (хәзерге Оренбург өлкәсе Шарлык районы) Мостафа авылында урта хәлле игенче гаиләсендә дөньяга килә. М.Җәлилнең әдәби мирасы, бигрәк тә тоткынлыкта иҗат иткән шигырьләре бөтендөнья поэзиясенең үзенчәлекле бер казанышы булып тора. Аның әсәрләре кешеләрдә матур, гуманистик тойгылар уята, аларны яшәешнең матурлыгын күрергә, аны кадерли белергә һәм аның өчен көрәшергә чакыра.

«Моабит дәфтәрләре» – Җәлил шигъриятенең иң югары ноктасы. Моабит шигырьләрендә шагыйрьнең шәхси образы, кичерешләре, фәлсәфи уйланулары аша кеше рухының бөеклеге, гуманистик табигате, гаделлек һәм хаклык тантанасына тирән ышанычы, туган халкына чиксез мәхәббәте гаҗәеп тәэсирле, эмоциональ көч һәм сәнгатьчә камиллек белән гәүдәләнә. Моабит шигырьләре Россиядәге барлык милли телләргә тәрҗемә ителүдән тыш, инглиз, француз, испан, алман, гарәп, төрек, кытай, япон, мадьяр, румын, чех һәм башка чит ил халыклары телләрендә дә кат-кат матбугатта басылалар.

Муса Җәлилнең тормыш һәм иҗаттагы батырлыгына багышлап йөзләрчә мәкаләләр, фәнни хезмәтләр, монографияләр язылган, әдәби әсәрләр-шигырьләр, поэмалар, романнар, драмалар һәм сәнгать әсәрләре иҗат ителгән.





Шагыйрьнең тууына быел 119 ел. Шул уңайдан зурлар төркеме белән "Герой шагыйрь-Муса Җәлил" дигән әдәби-музыкаль кичә узды. Әлеге чараның максаты-балаларны шагыйрь М.Җәлилнең тормышы һәм иҗаты белән таныштыру, шагыйрьнең Моабит төрмәсендә иҗат юлын һәм батырлыгын күрсәтү, шагыйрьнең биографиясен өйрәнү, фикерләү, күзаллау. Әлеге чара балаларга бик ошады: балалар бөек шагыйрьнең тормыш юлы турында презентация карадылар, шигырьләр сөйләделәр, җырлар җырладылар.

Хәзерге вакытта Ватаныбызның патриот гражданинын тәрбияләү бик мөһим. Безнең балалар үз геройларын – үз тормышларын геройларча бирүчеләрне, батырлык һәм каһарманлык күрсәтергә омтылучыларны белергә тиеш!!!











# 21 нче февраль –
# Халыкара туган тел көне



21 февральдә дөньякүләм туган тел көне билгеләп үтелә. ЮНЕСКО тарафыннан игълан ителгән әлеге халыкара бәйрәм дөньядагы телләрне саклау, аларны киләчәк буынга исән-имин җиткерү макстатыннан оеш-ты. Бүгенге көндә галимнәр Җир шарында 7 меңнән артык тел булуын әйтәләр. Һичшиксез, алар арасында миллиардлаган аралашучы һәм шул ук вакытта бер дистә кеше сөйләшә торган телләр дә бар. Хәзерге заманда күпчелегебез ким дигәндә 2-3 телне камил белә. Һәр халыкның теле үзенчәлекле, күп телләр белү дөньяга карашны киңәйтә, төрле милләт халкының мәдәниятен тирәнрәк белергә ярдәм итә. Ләкин туган тел ул бер генә. Безнең телебез – татар теле. Шуңа күрә һәр татар кешесе үз теленә хөрмәт белән карарга тиеш. Сабыйларыбызның теле туган телдә ачылсын. Телебезнең кулланылыш даирәсен киңәйтү, аны балаларыбызга һәм оныкларыбызга тапшыру – безнең төп бурычыбыз. Шул унайдан бакчабызда "Туган тел - халык җаны" дип исемләнгән бәйрәм кичәсе булып үтте. Мәктәпкә әзерлек төркемендә тәрбияләнүче балалар туган телдә матур итеп шигырьләр сөйләделәр, җырлар җырладылар. Кунакка килгән дәү әниебез балаларга Г. Тукай әкиятләре буенча сораулар бирде. Балалар бик актив һәм дөрес җаваплар бирделәр. Шулай ук дәү әни балаларны халкы-бызның уеннары белән таныштырды һәм уйнатты. Кичәне Габдулла Тукайның " Туган тел" җыры белән тәмамладык. Бәйрәм кичәсе бик күңелле узды.
Татар халык мәкале: “Туган телне кадерләгән халык кадерле булыр”, – ди. Туган телләребезне саклыйк, яклыйк, чөнки милләтнең яшәешендә туган тел иң мөһим урыннарның берсен алып тора.























# Ватанны саклаучылар көне

23 февраль көнне балалар бакчасында патриотизм хисен тәрбияләү, үз Ватаныңның иң яхшы традицияләрендә катнашу, Ватанны саклаучылар өчен горурлык хисен тәрбияләү өчен яхшы сәбәп булды.



Бу безнең Ватаныбыз сагында торган барлык кешеләрнең бәйрәме.
Бу чын ир-атлар бәйрәме - кыю һәм батыр, җитез һәм ышанычлы, шулай ук киләчәктә Ватанны саклаучы малайлар бәйрәме. Балалар белән үткәрелгән мондый чаралар аларның күңелләрендә патриотизм, Ватан алдындагы бурыч хисләрен уята.
Ел саен безнең балалар бакчасында "Ватанны саклаучылар көне" бәйрәменә тематик атна уза.
Атна дәвамында барлык яшь төркемнәрендә төрле чаралар үткәрелә: нәфис әдәбият уку, әңгәмәләр үткәрү, тема буенча иллюстрацияләр, слайдлар карау, хәрби техника турында табышмаклар чишү, гаскәрләрнең төрле төрләре турында сөйләшү, рәсем ясау. Тәрбиячеләр ярдәмендә балалар яраткан әтиләре, бабайлары, абыйлары өчен төрле материаллардан бүләкләр әзерлиләр.
Төркемнәрдә Ватанны саклаучылар көненә багышланган спорт бәйрәмнәре узды. Балалар җырлар җырладылар, биеделәр, шигырьләр сөйләделәр. Бәйрәм уен форма-сында узды һәм төрле эстафеталардан торды. Балалар зур активлык күрсәттеләр, бер-берсенә яхшы кәеф, аралашу һәм елмаю шатлыгы бүләк иттеләр, үзләренең җитез, чыдам, кыю булуларын күрсәттеләр. Ә кадерле бабайларына һәм әтиләренә бүләккә балалар җыр җырладылар, үз куллары белән ясаган «Корабль» открыткасын тапшырдылар.



Балалар бакчасында бәйрәм-олылар һәм балалар уртаклашкан шатлык, күңел ачу, тантана ул. Ул бала тормышына якты вакыйга булып керергә һәм хәтердә озакка калырга тиеш. Әгәр балалар бәйрәмнән соң үз тәэсирләре белән уртаклашырга ашыксалар һәм тагын күп көннәр аның тәэсире астында яшәсәләр – димәк, без максатыбызга ирештек. Бәйрәмнәр күңелле узды, һәм безнең тирәдәге дөнья бераз яктырак һәм мәрхәмәт-ләрәк булып китте!



















*Баш мөхәррир -- татар теленә өйрәтү буенча тәрбияче: Кәримова Гүзәл Рафаил кызы*
*Мөхәррир урынбасары - логопед Шәрипова Алсинә Хаҗиәхмәт кызы*